| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2020 Казан № 353-159/кс-2020

«Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнештәге су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Казаньоргсинтез» ГАҖ) өчен техник суга (әйләнештәге су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАҖ өчен техник суга (әйләнештәге су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары)

әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2021-2025 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 353-159/кс-2020 карарына
1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАҖ өчен техник суга (әйләнештәге су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны агызуга (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (әйләнештәге су белән тәэмин итү) (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык суларны агызуга тариф (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Казаньоргсинтез» ГАҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 0,98 | 10,98 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1,14 | 11,67 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1,09 | 11,59 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1,09 | 11,59 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1,09 | 11,59 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1,15 | 12,16 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1,15 | 12,16 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1,20 | 12,17 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 1,20 | 12,17 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 1,22 | 12,76 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 353-159/кс-2020 карарына
2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАЖ өчен техник суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Казаньоргсинтез» ГАЖ | | | | | | |
| 1.1 | Техник су (әйләнештәге су белән тәэмин итү) | 2021 | 222 653,71 | X | - | - | 0,21 |
| | | 2022 | X | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2023 | X | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2024 | X | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2025 | X | 1 | - | - | 0,21 |
| 1.2 | Ташландык су агызу (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) | 2021 | 32 391,64 | X | - | - | 0,74 |
| | | 2022 | X | 1 | - | - | 0,74 |
| | | 2023 | X | 1 | - | - | 0,74 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 | X | 1 | - | - | 0,74 |
| | | 2025 | X | 1 | - | - | 0,74 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге